


Һәр бишенче мошенник vз схемаларында мессенджерлар куллана.
2023 елда мондый һожvмнәр олеше ике тапкыр артты: 12 дән 22,5 процентка кадәр. Ни очен мошенниклар мессенджерларны бик яраталар?
Анда шикле шалтыратуларны фильтрлау системалары юк, кәрәзле элемтә (сотовая связь) операторларыннан аермалы буларак.
Әнгәмәдәш vзенен номерын яшерә ала, ә анын урынына теләсә нинди аватар һәм имза куя ала. Мәсәлән, банкнын исеме һәм логотибы, интернет-кибет, «Дәvләт хезмәтләре» порталы яки бу хакта белмәгән кешенен мәгълvматлары.      Мошенникларнын торле риваять-ләре булырга момкин: алар гадәттә vзләрен тикшерvчеләр, оешма яки ведомство хезмәткәрләре итеп кvрсәтәләр. Хәтта алар оешма хезмәткәрләренә житәкчелек исеменнән хат язалар. Аларнын максаты бер - акча һәм яшерен мәгълvмат алу. Шуна кvрә мәгълvмат гигиенасы кагыйдәләрен vтәv моһим - картанын тулы реквизитларын, СМС кодларын һәм башка яшерен мәгълvматны хәбәр итмәv. Һәм, әлбәттә, әгәр сезнен белән акча турында сойләшәләр һәм ашыгалар - мәгълvматны янадан тикшерергә. Бу хәбәр иске танышларнын берәр-сеннән булса да.
Yткән атнада Саранскида 13 яшьлек малай, уен валютасын сатып алу сылтавы белән, әнисенен банк картасыннан алдакчыларга 300 мен сумга якын акча кvчергән.
Россия Эчке эшләр министрлы-гынын Саранск шәһәре буенча 1 нче оп 42 яшьлек жирле хатын-кызга карата кылынган мошенниклык факты буенча тикшерv vткәрә.
Хатын-кыз сvзләренчә, 13 яшьлек улы, анын телефонында уйнаганда, билгесез кешенен уен валютасын сатып алу тәкъдименнән файдаланган. Билгесез кешеләрнен кvрсәтмәләре буенча, малай жинаятьчеләргә гариза бирvченен мобиль банкынын шәхси кабинетына керv момкинлеген биргән. Нәтижәдә, мошенниклар анын шәхси счетыннан 288 мен сум акча урлыйлар.
Исегезгә тошерәбез, берничә кон элек шулай ук жинаятьчеләр 46 яшьлек хатын-кызнын счетыннан 275 мен сум акча урлап, ана кредит картасы рәсмиләштергәннәр. Кvптән тvгел зыян кvрvче смартфонны 10 яшьлек кызына тапшыра, ул аны уйнарга сорый.
Хәзерге вакытта жинаятьләрнен шартлары һәм акча урлауда катнашы булган кешеләр ачыклана.
Эчке эшләр министрлыгынын Мордовия Республикасы буенча фәнни-тикшеренv институты ата-аналарга балаларга мобиль банк кушымтасы белән телефоннар тапшырмаска кинәш итә. Акча урламас очен, шәхси кабинетка керv очен ышанычлы серсvз куегыз һәм аны беркемгә дә әйтмәгез.